## Иске Шәйморзада иҗат отчет концерты узды…

Иске Шәйморза авыл мәдәният йортында 7 март көнне алма төшәргә дә урын юк иде. Концертта катнашучылар һәм аларны карарга килгән авыл халкы белән шыгырым тулы клуб умарта кучен хэтерлэтте. Һәрберсе үз эше белән мәшгуль иде: кемдер сәхнәгә чыгар алдыннан үзен тагын бер кат тәртипкә китерсә, кемдер фойеда урнашкан күргәзмә белән хозурланды.

Ниһаять беренче аккордлар. Кичәнең башында авыл җирлеге башлыгы Ильгам Сагит улы Бикчуров Бөек җиңүнең 70 еллыгына багышланган иҗади-йомгаклау концертына кереш сүз сөйләп, кичәне ачык диеп белдерде, һәм бәйрәмгә чакырылган сугыш һәм хезмәт ветераннары Абдрахман абый Камалетдинов һәм Әнвәр абый Фәхретдиновларга истәлек бүләкләре тапшырды.

Экранда күрсэтелеп барган Бөек Ватан сугышында Совет гаскәрләренең, шулай ук якташларыбызның күрсәткән чиксез батрлыгына багышланган видеороликны тамашачылар аягүрә басып алкышладылар.

Ә сәхнәдә халкыбыз моңнары Сабантуй бәйрәменә чакыра иде. Җыр-бию, төрле уеннар, ат чабышлары белән башланып киткән бәйрәмне сугыш залплары алыштырды. Сукса тимер өзәрдәй ир-егетләребез илебезне яклап яуга киттеләр. Ә авылда калган карт-коры, бала-чага тылдагы бөтен авырлыкны ничек күтәргәнне “Сөмбелә” фольклор ансамбле, сугышта вакытлыча тынлык урнашкан арада солдатларның ял итү күренешен сәхнәләштерделәр. Аларның чыгышларында Ватан-Анага булган тугрылык, якыннарына булган мәхәббәт, сагыну хисләрен чагылдырган шигырьләр, җырлар, биюләр тамашачыга чынбарлыкны күзалларга ярдәм итте.

Укытучылардан торган вокал төркем чыгышлары халкы тарафыннан югары бәяләнде. Сәхнәбез ветераннары Мәсхуть абый Басыйров, Альберт абый Идрисов, Казыйхан абый Шәмсетдинов, Әлфия Халитова, Роза Аксёнова, Тәлгат Җәббаров, Рамил Әбдрәкыйповның чыгышлары белән бер рәттән яшь җырчыларыбыз Айгөл Каюмова, Елена Еремеева, Дмитрий Глухов, Ангелина Аврелькина, Екатерина Задонская һәм башкаларның җырлаулары, өч төркемнән торган “Яшьлек” бию ансамбленең дәртле биюләре тамашачылар күңелендә якты эз калдырдылар.

Чарадан фоторепортаж:














07.03.2015

07.03.2015

70


70
07.03.2015

70

70
07.03.2015

70




07.03.2015

07.03.2015

70
07.03.2015

70

70

70

70
07.03.2015

07.03.2015

07.03.2015

70
07.03.2015


70
07.03.2015

07.03.2015


70

70

70


70


07.03.2015


70


70
07.03.2015


07.03.2015


70


70


70




70


70



















*Фәридә Җәббарова, Иске Шәйморза*